ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**11.12.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2412**

«Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасында гражданнарның торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә куюның исәп нормасын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексының 50 статьясына, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә куюның хисап нормасын гаиләнең бер әгъзасына торак урынның гомуми мәйданының 18 квадрат метрыннан кимрәк күләмдә билгеләргә.
2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә начальнигына массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев